# Әкияттә кунакта

21 январь көнне Бәзәкә балалар бакчасында авыл китапханәчесе “Әкияттә кунакта” дигән әдәби викторина үткәрде. Дөнья халыклары әкиятләре буенча әзерләнгән викторина сорауларына нәниләр дөрес җавап биреп тәрбиячеләрен дә, китапханәчене дә сөендерделәр. Аннары Ф.Башарова аларга “Дюймовочка” китабыннан могҗизалы әкиятләр укыды, бергәләп “Мороз Иваныч” әкиятен карадылар. Чара соңында китапханәче балалар белән бүгенге әкиятләрнең әһәмияте турында фикер алышты, укырга яңа китаплар биреп калдырды. (21.01.21)




«Грустно дед и бабка жили.
И дочурку себе слепили.
Она всегда им помогала,
Только вот огня избегала.»
Дюймовочка

